КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 20 август г.Казань № 715

Казан шәһәренең мәдәни мирас объектларын саклау зоналары, Казан шәһәренең мәдәни мирас объектларын саклауның берләшкән зоналары чикләрен, шулай ук җирләрдән файдалану режимнарын һәм әлеге зоналар чикләрендә шәһәр төзелеше регламентларына карата таләпләрне раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндәге мәдәни мирас объектларына карата саклау зоналары чикләрен, әлеге зоналар чикләрендә җирләрдән файдалану режимын һәм шәһәр төзелеше регламентларына карата таләпләрне расларга:

Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 98 нче йорт адресы буенча урнашкан «Кизик монастыренең Надвратная чиркәве», XVII гасыр федераль әһәмияттәге мәдәни мирас объектын 1 нче кушымта нигезендә;

Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Школьная урамы, 2а йорт адресы буенча урнашкан «Борисоглебск чиркәве», 1889 – 1897 еллар төбәк әһәмиятендәге мәдәни мирас объектын 2 нче кушымта нигезендә;

Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Николай Ершов урамы, 49 нчы йорт адресы буенча урнашкан «1893 елда Бехтерев Владимир Михайлович эшләгән округ психиатрия клиникасы», 1893 ел төбәк әһәмиятендәге мәдәни мирас объектын 3 нче кушымта нигезендә;

Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Юдино торак комплексы, Лейтенант Красиков урамы, «Дан аллеясы» паркы территориясендә, «Кызыл Тауны саклаучыларга» мемориаль комплексы артында урнашкан «Гражданнар сугышы герое Ян Юдин кабере», 1918 елның 12 августы төбәк әһәмиятендәге мәдәни мирас объектын 4 нче кушымта нигезендә;

Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Һади Атласи урамы, 28 нче йорт адресы буенча урнашкан «К.Л.Мюфке йорты», XIX гасыр төбәк әһәмиятендәге мәдәни мирас объектын 5 нче кушымта нигезендә;

Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Зеленая урамы, 1 нче йорт адресы буенча урнашкан «Казан гражданлык төзелеше инженерлары институты бинасы», 1930 – 1948 еллар ахыры төбәк әһәмиятендәге мәдәни мирас объектын 6 нчы кушымта нигезендә;

Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Нурсолтан Назарбаев урамы, 48 нче йорт адресы буенча урнашкан «Завод мәктәбе», 1934 ел төбәк әһәмиятендәге мәдәни мирас объектын 7 нче кушымта нигезендә;

Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Патрис Лумумумба урамы, 47а йорт адресы буенча урнашкан «Аэровокзал бинасы», 1954 ел, архитектор Н.Макарен төбәк әһәмиятендәге мәдәни мирас объектын 8 нче кушымта нигезендә;

Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, 1 нче Владимирская урамы, 42а йорт адресы буенча урнашкан «Казан Мәрьям Ана чиркәве», 1889 – 1890 еллар төбәк әһәмиятендәге мәдәни мирас объектын 1956 г.

Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Оренбург тракты урамы, 8 нче йорт адресы буенча урнашкан «ВДНХның төп павильоны бинасы», 1956 ел төбәк әһәмиятендәге мәдәни мирас объектын 10 нчы кушымта нигезендә;

Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Һади Такташ урамы, 112 нче йорт адресы буенча урнашкан «Казан зооботаника бакчасы», 1834 ел, 1931 ел региональ әһәмияттәге мәдәни мирас объектын 11 нче кушымта нигезендә;

Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Красная Горка торак массивы, Приволжская урамы, 32 нче йорт адресы буенча урнашкан «Никольская чиркәве», 1778 ел, 1828 ел, 1902 ел җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектын 12 нче кушымта нигезендә;

Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Краснококшайский урамы, 178 нче йорт адресы буенча урнашкан «Бөек Ватан сугышы фронтларында Ватан азатлыгы һәм бәйсезлеге өчен һәлак булган 66 нчы укчы корпусы, 18 нче укчы дивизиясе һәм 175 нче корпус лазареты сугышчыларына һәйкәл», 1986 ел җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектын 13 нче кушымта нигезендә;

2. Казан шәһәренең элеккеге Адмиралтейство бистәсе территориясендә урнашкан мәдәни мирас объектларын саклауның берләштерелгән саклау зонасы чикләрен, җирләрдән файдалану режимын һәм әлеге зона чикләрендә шәһәр төзелеше регламентларына карата таләпләрне 14 нче кушымта нигезендә расларга.

3. Казан шәһәренең элеккеге Яңа Татар бистәсе территориясендә урнашкан мәдәни мирас объектларын саклауның берләштерелгән саклау зонасы чикләрен, шулай ук әлеге зона чикләрендә җирләрдән файдалану режимын һәм әлеге зона чикләрендә шәһәр төзелеше регламентларына карата таләпләрне 15 нче кушымта нигезендә расларга.

4. Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Оренбург тракты урамы, 122 нче йорт, 4 нче корпус адресы буенча урнашкан «Шәһәр читендәге архиерей йортының яңа Тихвинская чиркәве», 1706 ел федераль әһәмияттәге мәдәни мирас объектының һәм Казан шәһәре, Оренбург тракты урамы, 122 нче йорт, 1 - 4 нче корпуслар адресы буенча урнашкан «Архиерей шәһәр яны йорты ансамбле (Воскресенск монастыре)»,

XVII – XIX гасыр төбәк әһәмияттәге мәдәни мирас объектының берләштерелгән саклау зонасы чикләрен, шулай ук әлеге зона чикләрендә җирләрдән файдалану режимын һәм шәһәр төзелеше регламентларына карата таләпләрне 16 нчы кушымта нигезендә расларга.

5. Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Һади Такташ урамы, 26 нчы йорт адресы буенча урнашкан «Кабан арты мәчетләрнең манаралы тәмамлану» федераль әһәмияттәге мәдәни мирас объектының һәм Казан шәһәре, Һади Такташ урамы, 28 нче йорт адресы буенча урнашкан «1942 елның март – июнь айларында формалашу чорында 120 нче укчы дивизиясе штабы урнашкан йорт» төбәк әһәмиятендәге мәдәни мирас объектының берләштерелгән саклау зонасы чикләрен, шулай ук әлеге зона чикләрендә җирләрдән файдалану режимын һәм шәһәр төзелеше регламентларына карата таләпләрне 17 нче кушымта нигезендә расларга.

6. Мәдәни мирас объектларын саклау буенча Татарстан Республикасы комитетына Казан шәһәре территориясендә урнашкан мәдәни мирас объектларын саклау зоналары, мәдәни мирас объектларының берләштерелгән саклау зоналары булу турында белешмәләрне Күчемсез милекнең бердәм дәүләт реестрына кертүне тәэмин итәргә.

7. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге карарлары үз көчен югалткан дип санарга:

«Казан шәһәренең мәдәни мирас объектларын саклау зоналары чикләрен, әлеге зоналар чикләрендә җирләрдән файдалануның махсус режимнарына һәм шәһәр төзелеше регламентларына карата таләпләрне раслау турында» 2016 ел, 3 ноябрь, 815 нче;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Казан шәһәренең мәдәни мирас объектларын саклау зоналары чикләрен, әлеге зоналар чикләрендә җирләрдән файдалануның махсус режимнарына һәм шәһәр төзелеше регламентларына карата таләпләрне раслау турында» 2016 ел, 3 ноябрь, 815 нче карарына 1.5 «Мәдәни мирас объектларын саклау зоналары тасвирламасы» кушымтасына үзгәреш кертү хакында» 2018 ел, 28 август, 727 нче.

6. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Мәдәни мирас объектларын саклау буенча Татарстан Республикасы комитетына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин